| | |
|---|---|
| ГЛАВА ИЛЯКСАЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИЛЕКСАЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

3 ноябрь 2023 ел Илексаз авылы № 4

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Илексаз авылы өлешендә 2024 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Илексаз авылы, Комсомольская урамы, 2 нче йорт адресы буенча урнашкан Илексаз авылы мәдәният йорты бинасында 2023 нче елның 15 нче ноябренә 10 сәгатьтә Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Илексаз авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләп кую.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: I нче группа инвалидлар, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан кала, Илексаз авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2024 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

1) Илексаз авылында юл корылмаларын буяу өчен буяулар сатып алу, юл билгеләре салу;

2) Илексаз авылы, Яшьләр урамы, авыл эчендәге юлларны ремонтлау (таш ташу);

3) Илексаз авылында "Беларус 82.1" тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү) ;

4) Илексаз авылында җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (шофер хезмәтенә түләү);

5)Илексаз авылында урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (материаллар сатып алу);

6) янгын куркынычсызлыгы өчен җиһазлар сатып алу (мотопомпа өчен запас частьләр, сулык өчен материаллар сатып алу);

7) Илексаз торак пунктының янгын сулыклары дамбасын киңәйтү өчен туфрак ташу;

8) юл кырыен кисү (ягулык-майлау материаллары сатып алу, йөртүче хезмәтенә түләү);

9) Илексаз авылында күпләп ял итү урыннарын ремонтлау (материаллар, сәхнәләр сатып алу);

10) Илексаздан һәйкәлләрне ремонтлау (материаллар сатып алу).

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Илексаз авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында, http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга .

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы

Илексаз авыл җирлеге башлыгы: Гыйльфанов Ф. М.